**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» 2014 елның 25 февралендәге ПУ-217 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 22 ноябрендәге ПУ-1065 номерлы, 2015 елның 30 июлендәге ПУ-688 номерлы, 2017 елның 20 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-459 номерлы, 2017 елның 14 октябрендәге ПУ-911 номерлы, 2019 елның 2 февралендәге ПУ-58 номерлы, 2020 елның 5 июнендәге ПУ-339 номерлы, 2021 елның 18 февралендәге ПУ-154 номерлы, 2021 елның 2 мартындагы ПУ-194 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 25 июлендәге 506 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбулада «рәсми булмаган хезмәт базарын киметү һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәдә:

1 пунктта «рәсми булмаган хезмәт базарын киметү һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта:

өченче абзацны төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «рәсми булмаган икътисадның һәм хезмәт базарының» сүзләрен «яшерен икътисадның» сүзләренә алмаштырырга;

в) Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан И.Ф. Бәдриевны, Р.Ә. Галәвовны, А.Д. Гариповны, А.Г. Никиташинны, М.А. Патяшинаны, Л.Н. Шәйхетдинованы, К.Г. Яковлевны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Вәлиуллин Ренат Нәкыйф улын – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

Виниченко Владислав Валентиновичны – Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесен (килешү буенча);

Зәйнетдинова Алсу Хәмит кызын – Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны (килешү буенча);

Нәбиуллина Лилия Мөхәммәт кызын – Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Прокофьева Марина Викторовнаны – Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Степанова Елена Юрьевнаны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы урынбасарын;

Фатыйхов Илдар Разин улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасарын;

Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.М. Карповның – «Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары»;

А.В. Сабурскаяның – «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы, Комиссия секретаре».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 565